**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«27» март 2017 ел № 13/3

**Тукай муниципаль районында демографик вәзгыятьне яхшырту чаралары турында**

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге җитәкчесе Э. Р. Мостафинаның «Тукай муниципаль районында демографик хәлне яхшырту чаралары турында» мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.
2. Район Башкарма комитетына:
- балаларның тууын тулысынча һәм үз вакытында теркәүне тәэмин итү максатларында Чаллы шәһәренең Башкарма комитеты каршында районның ГХАТ бүлеге белгече өчен эш урынын оештыру мәсьәләсе буенча «2 нче поликлиника» ДАССУ учреждениесенә мөрәҗәгать итәргә.
- аерылышучылар санын минимальләштерү максатларында үсеп килүче яшь буынны тәрбияләүгә бердәм якын килүне булдыру бүлекләренең үзара хезмәттәшлеген оештырырга.
- гражданнарны кабул итү шартларын тәэмин итү максатларында район хакимияте бинасында ГХАТ бүлегенә өстәмә мәйдан бүлеп бирү мәсьәләсен карарга.
3. Авыл җирлекләре башлыкларына гражданның үлүе турында үз вакытында хәбәр итүне һәм үлем турында таныклык булганда гына күмүне оештыруны тәкъдим итәргә..
4. Тукай районы үзәк хастаханәсенә эшне дәвам итәргә тәкъдим итәргә:
   - үлем авыруларын иртә кисәтү һәм ачыклау, халыкны үз вакытында диспансерлаштыруга максималь җәлеп итү буенча.
   - балигъ булмаганнарның иртә йөклелекләрен профилактикалау һәм җенси юл белән тапшырыла торган авыруларны кисәтү буенча.
5. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә гаилә кыйммәтләрен, милли гореф-гадәтләрне популярлаштыру, сәламәт яшәү рәвешен алып бару буенча материаллар бастыру буенча даими рубрика алып барырга тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев